ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2026 с.Старое Дрожжаное №92

2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программага үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 06 февралендәге 34 номерлы карары белән расланган 2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программага, «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа нәтиҗәләрен бәяләүнең индикаторлары, максатлары, бурычлары һәм Программа чаралары буенча финанслау» кушымтасының **3 бүлеген** яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

<table>
<tr><td colspan="15">3 нче бурыч: иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән һәм җәзалары иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган хөкем ителгән затлар белән профилактик эш оештыру, шул исәптән «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль законның 06.02.2023 елның 10-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (пробация кулланганда)</td></tr>
<tr><td>3.1. Дини конфессияләр вәкилләрен ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, алкоголизм һәм наркомания белән интегүче затларны социаль тернәкләндерү эшенә җәлеп итәргә</td><td>Мухтасибат һәм Благочинный ,ФКУ УИИ УФСИН Татарстан Республикасы буенча (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча)</td><td>2026-2030 еллар</td><td rowspan="2">Элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма авырлыгы, тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми саны (процентл</td><td rowspan="2">21,4</td><td rowspan="2">20,6</td><td rowspan="2">20,2</td><td rowspan="2">19,8</td><td rowspan="2">19,4</td><td rowspan="2">19,0</td><td>0,02</td><td>0,02</td><td>0,02</td><td>0,02</td><td>0,02</td></tr>
<tr><td>3.2. Төрмәдән азат ителгән кешеләргә эшкә урнашуда ярдәм күрсәтергә.</td><td>ЦЗН, УСЗ, ФКУ УИИ УФСИН России по РТ (килешү буенча)</td><td>2026-2030 еллар</td><td>0,04</td><td>0,04</td><td>0,04</td><td>0,04</td><td>0,04</td></tr>
</table>

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ар) | | | | | | | | | | | |
| **3.3.** Социаль элемтәләрне торгызуда, формалаштыруда һәм ныгытуда, социаль һәм хокукый мәсьәләләр буенча консультацияләр бирүдә, юридик һәм психологик ярдәм күрсәтергә. | ЦЗН, УСЗ, ФКУ УИИ УФСИН России по РТ (килешү буенча) | 2026-2030 еллар | | | | | | | | - | - | - | - | - |
| **3.4.** Ярдәм күрсәтергә: пробация кулланыла торган зат үз хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны алганда;<br>гомуми белем алуда, урта һөнәри белем алуда, һөнәри белем алуда, квалификациясен күтәрүдә;<br>эшсезлек буенча пособие алуда;<br>РФ законнары нигезендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме алуда;<br>медицина ярдәме алуда;<br>пенсия тәэмин ителешен алуда;<br>социаль хезмәтләр алуда;<br>яшәү урыны булмаганнарга вакытлыча яшәү урыны һәм/яки ризык бирүдә;<br>башка ярдәм алуда. | ЦЗН, УСЗ, ФКУ УИИ России по РТ (килешү буенча), ЦРБ (килешү буенча), ПФР, РОО һәм профилактиканың башка субъектлары (килешү буенча) | 2026-2030 еллар | | | | | | | | - | - | - | - | - |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов